**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1038**
**19.02.2024**

Башкарма комитетның 2022 елның 21 гыйнварындагы 224 номерлы Карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 21 гыйнварындагы 224 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 26 маендагы 4327 номерлы Карары редакциясендә) расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.6.1 пунктның 10 пунктчасында «социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов